| | | |
|---|---|---|
| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

20.07.2015 № 201

**Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитетына гражданнардан һәм оешмалардан килгән мөрәҗәгатьләрне анализлау Тәртибе турында**

«Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында» 2003 елның 11 апрелендәге 16-ЗРТ санлы Татарстан Республикасы Законының 23 статьясы нигезендә,

б о е р а м:

1. Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитетына (алга таба Дәүләт комитеты) гражданнардан һәм оешмалардан килгән мөрәҗәгатьләрне анализлауның бирелгән Тәртибен расларга.
2. Гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү бүлегенә (О.В.Давыдова) гражданнардан һәм оешмалардан килгән мөрәҗәгатьләргә анализны (алга таба-анализ) елга ике мәртәбә, яртылыкның соңгы аеннан соң килгән айның 15 числосына кадәр башкарырга.
3. Информатизацияләштерү бүлегенә (М.Х.Абайдуллин) күрсәтелгән анализны гражданнар һәм оешмалар мөрәҗәгатьләре буенча хисаплар һәм мәгълүматлар алынганнан соң 3 көн эчендә Дәүләт комитетының рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.
4. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Рәис М.Р.Зарипов

Татарстан Республикасы
тарифлар буенча Дәүләт
комитеты боерыгы белән
расланган
20.07.2015 ел. № 201

Татарстан Республикасы тарифлар буенча
Дәүләт комитетына гражданнардан һәм оешмалардан килгән
мөрәҗәгатьләрне анализлау
Тәртибе

1. Әлеге Тәртип «Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында» 2003 елның 11 апрелендәге 16-ЗРТ санлы Татарстан Республикасы Законының 23 статьясын үтәү йөзеннән эшләнгән һәм Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитетына (алга таба - Дәүләт комитеты) гражданнардан һәм оешмалардан килгән мөрәҗәгатьләрне гомумиләштерү һәм анализлау процедурасын билгели.

2. Анализ үткәрү барышында килгән, башка адрес буенча юнәлтелгән һәм каралган язма мөрәҗәгатьләр, электрон документ рәвешендә килгән мөрәҗәгатьләр саны, гражданнарны кабул итү урыны, көне, сәгате, шәхсән кабул ителгән гражданнар саны, гражданнарны шәхсән кабул итү һәм шәхси күчмә кабул итү буенча вәкаләтле затлар, мөрәҗәгатьләр тематикасы, мөрәҗәгатьләрне карау нәтиҗәләре буенча кабул ителгән чаралар турындагы мәгълүмат, шул исәптән кабул ителгән норматив хокукый һәм башка актлар(булганда) турындагы мәгълүмат, шулай ук, Татарстан Республикасы муниципаль районнары буенча бүленгән мөрәҗәгатьләр тематикасы турындагы мәгълүмат өйрәнелә.

3. Мөрәҗәгатьләрне гомумиләштерү һәм анализлау Дәүләт комитетының гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү бүлеге (алга таба - Бүлек) тарафыннан, электрон документ әйләнеше мәгълүматлары һәм әлеге Тәртипнең 4 һәм 5 пунктлары нигезендә алынган мәгълүматлар нигезендә башкарыла.

4. Җитәкченең шәхсән кабул итү барышында алынган һәм Дәүләт комитетының структур подразделениеләренә турыдан-туры килгән мөрәҗәгатьләр турындагы мәгълүмат, шул исәптән күчмә кабул итүләр буенча алынган мәгълүмат гражданнарны шәхсән кабул итү исемлегенә керткән белгеч тарафыннан шәхсән кабул итү көненнән килгән ике көннән дә соңга калмыйча Бүлеккә тапшырыла.

5. Телдән бирелгән консультацияләр һәм гражданнарның кабул итү буенча тутырылган исәпкә алу карточкалары Дәүләт комитетының структур подразделениеләре җитәкчеләре тарафыннан хисап аеннан соң килгән айның 1 числосыннан дә соңга калмыйча Бүлеккә юнәлтелә.

6. Бүлек башлыгы 3 пунктта күрсәтелгән мәгълүматны, шулай ук әлеге Тәртипнең 4 һәм 5 пунктлары нигезендә килгән мәгълүматны кергән көннән

алып 2 көн эчендә гомумиләштерүне һәм анализлауны башкара һәм анализны рәис урынбасары (Д.А.Симкачев) белән килештерә.

7. Мөрәҗәгатьләргә анализлар Дәүләт комитетының рәсми сайтында урнаштыру өчен информатизацияләштерү бүлегенә юнәлтелә. Анализ гражданнар һәм оешмалар мөрәҗәгатьләре буенча хисаплар һәм мәгълүматлар алынганнан соң 3 көн эчендә Дәүләт комитетының рәсми сайтында урнаштырыла.

8. Гражданнардан килгән мөрәҗәгатьләргә анализ ачык мәгълүмат булып тора һәм аның белән Дәүләт комитетының рәсми сайтында ирекле танышып була(http://kt.tatarstan.ru).